КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 май г.Казань № 331

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 16 апрель, 256 нчы; 2024 ел, 10 декабрь, 1125 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законда, «Гаилә» илкүләм проекты составына керә торган «Күпбалалы гаилә» федераль проектында билгеләнмәгән өлештә социаль контракт нигезендә федераль бюджеттан финанслашу шартларында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү» 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 нче карары нигезендә, шулай ук тормышта авыр хәлдә калган затларга адреслы социаль ярдәм формаларының нәтиҗәлелеген арттыру, аларны җиңеп чыгу өчен актив гамәлләр кылуга стимуллау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гаиләнең җан башына уртача керемен, ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләү, аз керемле гаилә составын билгеләү «Гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу тәртибе турында, аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керем төрләренең һәм ялгыз яшәүче гражданның аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары нигезендә исәпләнә.

Аз керемле гаилә әгъзасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждан булса, аз керемле гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәмнең кайбер чараларын, социаль контракт нигезендә социаль ярдәм күрсәтү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 29 октябрендәге 1933 номерлы карарының 1 пунктын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хокукын билгеләгәндә һәм гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган гаилә составына түбәндәгеләр кертелми:

а) тулысынча дәүләт тәэминатында булган затлар (гариза бирүчедән, шулай ук аның опекасындагы яисә попечительлегендәге балалардан, җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда белем алучы һәм яшәүче балалардан тыш);

б) хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү хәрби мәгариф оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

в) иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәгән затлар;

г) суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затлар;

д) сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы кулланылган затлар;

е) хәбәрсез урында булмаган дип танылган яисә үлгән дип игълан ителгән затлар;

ж) эзләнә торган затлар;

з) гариза бирүченең балигъ булмаган балалары, гариза бирүче опекасындагы (попечительлектәге) балалар, гариза бирүченең гомуми белем бирү оешмасында,

һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү мәгариф оешмасының көндезге бүлегендә белем алучы, никахлашкан 23 яшькә кадәрге балалары.»;

5 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территориаль социаль яклау органында теркәлгән билгеләү турында гариза, шулай ук илтеп тапшыру ысулын үзгәртү турында гариза булганда шул ук гариза бирүче тарафыннан кабат бирелгән билгеләү турында гариза, шулай ук илтеп тапшыру ысулын үзгәртү турында гариза кабул ителми.»;

6 пунктның икенче абзацында «көненнән алып биш эш көне» сүзләрен «вакыттан алып 48 сәгать» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «гаиләнең җан башына уртача кереме, ялгыз яшәүче гражданның кереме» сүзләрен «аз керемле гаиләнең җан башына уртача кереме, ялгыз яшәүче гражданның кереме» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Социаль контрактка түбәндәге чаралар карала торган социаль адаптация программасы теркәлә:

а) эш эзләү буенча;

б) индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча;

в) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча;

г) гражданның авыр тормышта хәлен җиңеп чыгуына юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыру буенча (бертип авыр тормыш хәлләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелә).

Башка чаралар дигәндә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга булган агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 178-ФЗ номерлы Федераль закон) 12 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацында каралган дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар аңлашыла.

Социаль контракт күпбалалы гаиләләр, балалы гаиләләр һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучылар белән, шулай ук аларның гаилә әгъзалары белән өстенлекле рәвештә төзелә.

Бер үк граждан (бер үк гаилә) белән социаль контракт, сайлап алынган чараның нинди булуына карамастан, әлеге Нигезләмәнең 43 пункты нигезендә элек төзелгән социаль контракт тәгалләнгәннән соң үткәрелә торган гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) тормыш шартларына мониторинг ясалган көннән иртәрәк булмаган вакытта төзелә (территориаль социаль яклау органы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 43 пунктындагы икенче пункт нигезендә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) тормыш шартларына мониторинг үткәрү чорында граждан (гаилә) белән яңа социаль контракт төзү максатка ярашлы булу турында карар чыгарылган очрактан тыш).

Социаль адаптация программасы дәүләт социаль ярдәмен алучы тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен мәҗбүри чараларны күздә тота.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Территориаль социаль яклау органы тарафыннан социаль контракт, социаль адаптация программасы һәм аңа теркәлә торган материаллар, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-план (чыгымнар сметасы) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) утырышында социаль контракт төзегәнгә кадәр карала.

Ведомствоара комиссияләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә төзелә; аларның составларына социаль контракт төзүне хуплау (хупламау) турында килештерелгән фикерне, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яисә әлеге документларны эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикерне әзерләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары, территориаль социаль яклау органнары, җирле үзидарә органнары, икътисад бүлекләре, опека һәм попечительлек органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре, башка органнар һәм оешмалар вәкилләре керә.

Ведомствоара комиссия тапшырылган документларга бәя бирә, кирәк булганда, социаль адаптация һәм (яисә) бизнес-план программасын эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр һәм тәкъдимнамәләр бирә, социаль контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә әзерли.

Ведомствоара комиссия тарафыннан социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикер эшләнгән очракта, мондый документлар территориаль социаль яклау органы тарафыннан, гариза бирүче белән берлектә, эшләп бетерелә һәм әлеге килештерелгән фикер тапшырылган көннән алып биш эш көненә кадәр ведомствоара комиссиягә кабат карауга кертелә.

Ведомствоара комиссия вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

ведомствоара комиссия утырышында социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) карап тикшерү;

территориаль социаль яклау органына социаль контракт, социаль адаптация программасы буенча, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән чаралар составы буенча, һәм (яисә) аңа теркәлә торган материаллар, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-план (чыгымнар сметасы) буенча искәрмәләр кертелә;

әлеге пунктның дүртенче абзацы нигезендә эшләнеп беткән социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) кабат карап тикшерү;

әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә социаль контракт төзүне хуплау (хупламау), социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган

материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яисә әлеге документларны эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикерне әзерләү.

Ведомствоара комиссия утырыш көнендә көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карап тикшерә һәм түбәндәге карарны кабул итә:

социаль адаптация программасын һәм (яисә) бизнес-планны раслау турында һәм гариза бирүче белән социаль контракт төзүне киңәш итә;

социаль адаптация программасы проектына һәм бизнес-планга үзгәрешләр кертүне (конкрет тәкъдимнәрне күрсәтеп) тәкъдим итәргә;

сайланган эшчәнлек төренең икътисадый нәтиҗәле булмау сәбәпле, социаль адаптация программасын гамәлгә ашыруның һәм гариза бирүче белән социаль контрактны гамәлгә ашыруның максатка ярашсызлыгы турында (мондый карарны кабул итү өчен мотивлаштырылган нигезләмә белән).

Ведомствоара комиссия социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган бизнес-планны (чыгымнар сметасын) хупламау турында карар кабул итәргә хокуклы.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган документларны территориаль социаль яклау органына тапшырган көннән алып биш эш көне үткәнгә кадәр ведомствоара комиссия утырышы уздырыла, аның нәтиҗәләре буенча комиссия утырышында рәислек иткән зат һәм ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә рәсмиләштерелә һәм территориаль социаль яклау органына җибәрелә.

Әлеге Нигезләмәнең 2 – 5 нче кушымталарында бирелгән формалар буенча социаль контракт төзү ведомствоара комиссия тарафыннан гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптация программасы һәм бизнес-план (чыгымнар сметасы) раслаганнан соң гамәлгә ашырыла.»;

18 пунктның икенче абзацында «вакыттан» сүзен «көненнән» сүзенә алмаштырырга;

19 пунктның икенче абзацында «вакыттан» сүзен «көненнән» сүзенә алмаштырырга;

24 пунктта:

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) әлеге Нигезләмәнең 55 пункты нигезендә социаль контракт буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүчеләр саны бүленешен үтәү максатларында территориаль социаль яклау органы өчен билгеләнгән, әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүчеләрнең санына ирешү;»;

«л» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«л) гариза бирүченең авыр тормыш хәлендә булмавы яисә аның әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелә торган гаиләләр (ялгыз яшәүче граждannар) категориясенә туры килмәве;»;

«м» пунктчасына «, яисә гариза бирүче әлеге Нигезләмәнең 34 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә эшкуарлык компетенцияләрен үстерү өчен укуны

уңышлы узуны раслый торган сертификатны яисә башка документны алмаган очракта, гариза бирүче социаль адаптация программасында каралган төп чараны үзгәртүдән баш тарту»; сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «н» – «т» пунктчалары өстәргә:

«н) гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен тест үтүдән баш тартуы;

о) гражданның әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча әлеге Нигезләмәнең 53 пункты нигезендә индивидуаль эшкуар буларак теркәлү яисә Татарстан Республикасыннан читтә үз эшчәнлеген һөнәри керемгә салым түләүче буларак гамәлгә ашыруы (гамәлгә ашыруны планлаштыру);

п) ведомствоара комиссиянең социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук бизнес-планны (чыгымнар сметасын) хупламау турында килештерелгән фикере;

р) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында каралган чаралар буенча билгеләү турында гариза биргән айга кадәрге 12 ай эчендә гариза бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органыннан «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты нигезендә эшсез гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык итүгә күрсәтелә торган бер тапкыр финанс ярдәме алу;

с) әлеге Нигезләмәнең 43 пункты нигезендә элек төзелгән социаль контракт тәгалләнгәннән соң үткәрелә торган гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) тормыш шартларына мониторинг үткәрү чорында граждан (аның гаиләсе) тарафыннан гариза бирү (территориаль социаль яклау органы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 43 пунктындагы беренче пункт нигезендә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) тормыш шартларына мониторинг үткәрү чорында граждан белән яңа социаль контракт төзү максатка ярашлы булу турында карар чыгарылган очрактан тыш);

т) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган зат тарафыннан билгеләү турында гариза бирелү.»;

25 пунктта:

«б» пунктчасында «һәм мониторинг» сүзләрен төшереп калдырырга;

«к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) гариза бирүче тарафыннан территориаль социаль яклау органына әлеге Нигезләмәнең 43 пунктындагы беренче абзацы нигезендә элек төзелгән социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг ясауны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар (белешмәләр) тапшырылмау, әгәр әлеге документларны алар белән эш итә торган органнарда һәм (яисә) оешмаларда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, алып булмаса.»;

27 пунктта:

беренче абзацта «25 пунктның «а», «в», «д», «ж» һәм «з» пунктчаларында» сүзләрен «25 пунктның «а» – «в», «д», «ж» һәм «з» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 25 пунктындагы «г», «е», «и» һәм «к» пунктчаларында күрсәтелгән хәлләр элек төзелгән социаль контракт тәгәлләнү буенча гамәлгә ашырыла торган гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг ясау тәгәлләнгән көннән башлап 12 ай эчендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен өстәмә нигез булып тора.»;

31 пунктта түбәндәге эчтәлекле «$к^1$» һәм «$к^2$» пунктчалары өстәргә:

«$к^1$) социаль контракт гамәлдә булган чорда индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвен туктату яисә индивидуаль эшкуар булмаган гражданны салым органында һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәптән төшерү;

$к^2$) 44-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезендә билгеләнә торган билгеләү турында гариза бирелгән датага исәп-хисап чорында әлеге Нигезләмәнең 24 пунктында күрсәтелгән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булуы ачыклану;»;

34 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән очракта, төп чараны үзгәртү максатларында территориаль социаль яклау органы, гариза бирүче белән килештереп, социаль адаптация программасына, билгеләү турындагы гаризаны кабат бирмичә һәм гариза бирүченең 178-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә туры килүен бәяләмичә, үзгәреш кертә.»;

39 пунктның «г» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәне гамәлгә ашыру максатларында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) авыр тормыш хәлен җиңеп чыгуы дип социаль адаптация программасын тулы күләмдә билгеләнгән срокларда үтәү дип танылa.»;

43 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43. Территориаль социаль яклау органы социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг үткәрә.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) тормыш шартларына мониторинг ясау барышында алынган нәтиҗәләр буенча территориаль социаль яклау органы граждан белән яңа социаль контракт төзүнең яисә аңа (аның гаиләсенә) социаль ярдәмнең яисә хезмәт күрсәтүләрнең башка чараларын күрсәтүнең максатка ярашлы булуы турында карар кабул итә.

Яңа социаль контракт, элек төзелгән социаль контрактны түбәндәге сәбәпләр буенча нәтиҗәсез дип танылган очракта, граждан белән гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг үткәрү чорында төзелергә мөмкин:

эш бирүче инициативасы буенча хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату;

авыру (өч айдан артык стационар, амбулатор дәвалану);

табигый характердагы җиңеп булмаслык хәлләр (су басулар, җир тетрәүләр һәм башка табигый катаклизмнар);

кешеләрнең җитештерү эшчәнлегенә бәйле вакыйгалар (янгыннар, техноген аварияләр, су белән тәэмин итү, җылылык, электр белән тәэмин итү системаларында аварияләр һ.б.);

гражданны (гаилә әгъзасын) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру;

махсус хәрби операциядә катнашу өчен граждан (гаилә әгъзасы) белән «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясы нигезендә хәрби хезмәт үтү турында контракт, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 221 статьясы нигезендә ирекле формированиедә булу турында контракт төзү.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг үткәрелә, шул исәптән:

а) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

ай саен 12 ай дәвамында гамәлдәге хезмәт шартнамәсе (хезмәт контракты) булу факты тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гражданның хезмәт эшчәнлегеннән уртача кереме исәпләнә;

б) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

ай саен 12 ай дәвамында гражданның индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алыну яки салым органында һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә куелу факты тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гражданның эшкуар эшчәнлегеннән уртача кереме исәпләнә;

в) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

ай саен 12 ай дәвамында гражданның салым органында һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә куелу факты тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гражданның әзхси ярдәмче хуҗалык алып барудан уртача кереме исәпләнә;

г) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча – квартал саен 12 ай дәвамында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) матди-көнкүреш хәле начарлану факты тикшерелә.»;

45 пунктта түбәндәге эчтәлекле «и» пунктчасы өстәргә:

«и) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 26 пунктына кермәгән, нигезле булмаган сәбәпләр буенча социаль адаптация программасы чаралары үтәлмәгән (үз вакытында үтәлмәгән) очракта, социаль контракт төзү датасыннан бер ай эчендә бирелә торган,

дәүләт социаль ярдәме буларак алынган акчалата түләүне 30 календарь көн эчендә тулы күләмдә кире кайтарырга.»;

47 пунктның «е» пунктчасында «30 көн эчендә» сүзләрен «30 календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

49 пунктның «ж» пунктчасында «30 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «30 календарь көн дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

51 пунктның «в» пунктчасындагы икенче абзацында «әлеге пунктчаның беренче абзацы» сүзләрен «әлеге пунктның «б» пунктчасы» сүзләренә алмаштырырга;

56 пунктта:

беренче абзацта «Гражданнарга адреслы социаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе субъектларына ярдәм» федераль проекты» сүзләрен «Гаилә» илкүләм проекты составына керә торган «Күпбалалы гаилә» федераль проекты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары белән расланган «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 61 пункт өстәргә:

«61. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме сыйфатында алынган акчаны кире кайтару максатларында, әлеге Нигезләмәнең 47 пунктындагы «е» пунктчасы һәм 49 пунктындагы «ж» пунктчасы нигезендә халыкны социаль яклау органы тарафыннан территориаль социаль яклау органы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүченең дәүләт социаль ярдәме сыйфатында алынган акчаны кире кайтару бурычын китереп чыгарган шартларны ачыклаган көннән алып биш эш көне эчендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүчегә әлеге акчаны 30 календарь көнгә кадәр кире кайтару кирәклеге турында хәбәрнамә җибәрелә.

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан акча кире кайтарылмаган очракта, халыкны социаль яклау органы мондый акчаны суд тәртибендә түләтә.»;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гариза биргән датага кадәр 6 ай дәвамында 3 айдан артык гражданның һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының өзлексез дәвалануы.»;

9 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында:

3.2 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нигезле булмаган сәбәпләр буенча социаль адаптация программасы чаралары үтәлмәгән (үз вакытында үтәлмәгән) очракта, социаль контракт төзү датасыннан алып бер ай эчендә бирелә торган, дәүләт социаль ярдәме буларак алынган акчалата түләүне, шулай ук хокуксыз алынган акчаны Вәкаләтле органның хәбәрнамәсен (таләбен) алган көннән алып 30 календарь көн эчендә тулы күләмдә Вәкаләтле органга кире кайтарырга.»;

6.2 пунктта «карала торган социаль адаптация программасы формасының» сүзләрен «карала торган социаль адаптация программасының» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 6.2 пунктында «карала торган социаль адаптация программасы формасының» сүзләрен «карала торган социаль адаптация программасының» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтаның 6.2 пунктында «карала торган социаль адаптация программасы формасының» сүзләрен «карала торган социаль адаптация программасының» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтаның 6.2 пунктында «карала торган социаль адаптация программасы формасының» сүзләрен «карала торган социаль адаптация программасының» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин